**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422701, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Высокая Гора, ул. Юбилейная, 1А

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИЕКТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422701, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау  авылы, Юбилей ур., 1А

Тел./факс: +7(84365) 74-7-79, e-mail: Vgor.Vsg@tatar.ru

---

КАРАР РЕШЕНИЕ

23 январь 2020 ел 647 нче номер

Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының аерым карарларының   үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге ФЗ-131нче номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның

28 июлендәге ТРЗ-45нче номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча  Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

• Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2011 елның 25 февралендәге 66 номерлы «Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге башлыгы һәм администрациясенең хокукый актлары күчермәләрен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарын.

• Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2011 елның 25 февралендәге 6в номерлы «Биектау авыл җирлеге Башкарма комитетында белешмәләр, йорт кенәгәсеннән өземтәләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында " карарын.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында, Биектау муниципаль районы рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru адресы буенча авыл җирлеге бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.

Совет рәисе,

Биектау авыл җирлеге Башлыгы Ю.М.Галимов